| | |
|---|---|
| **Совет Большеачасырского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы** |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 30 сентябрь 2020 ел | №8 |

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт өчен түләү, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында" карары нигезендә, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. 2020 елның 1 октябреннән:

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына ай саен 15 759 (унбиш мең җиде йөз илле тугыз) сум күләмендә акчалата вознаграждение түләүне һәм 8826 (сигез мең сигез йөз) сум күләмендә ай саен акчалата поощрение түләүне билгеләргә.

2. 2020 елның 1 октябреннән ел саен түләнә торган отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен:

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы "Олы Ачасыр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгына 15 759 (унбиш мең җиде йөз илле тугыз) сум күләмендә билгеләргә;

3. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен кушымта нигезендә билгеләргә.

4. Әлеге карарның 1-3 пунктларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итү тиешле елга Олы Ачасыр авыл җирлеге бюджетында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. 2020 елның 1 октябренән Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип санарга:

- 2018 елның 25 апрелендәге 144 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт өчен түләү, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»;
- 2018 елның 26 октябрендәге 179 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт өчен турында».

6. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**

Олы Ачасыр авыл җирлеге
Советының 2020 елның 30
сентябрендәге 8 номерлы
карарына кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ РАЗМЕРЛАРЫ

| Муниципаль хезмәт вазыйфаларының исемнәре | Айлык вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) | 15 293 |